
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы

№7
Март, 2020 г.



## С Международным женским днем!

Среди весенних первых дней
8 Марта всех дороже.
На всей земле, для всех людей
Весна и женщины похожи.

Успехов Вам, здоровья Вам
И счастья пожелаем
И с первым праздником весны
Сердечно поздравляем.

Пусть отблеск зимний еще не угас,
Но воздух становится зыбким.
С Женским весенним праздником Вас,
С первой весенней улыбкой!




## Клара Цеткин - женщина, придумавшая праздник 8 Марта.

**Клара Цеткин была активным борцом за права женщин. Ее имя неразрывно связано с празднованием Международного женского дня.**

Одна из самых известных деятельниц немецкого и международного социалистического и женского движения Клара Цеткин (Clara Zetkin) вошла в историю XX века не только как активная коммунистка, но и как женщина-реформатор, сыгравшая немаловажную роль в становлении европейского движения за права женщин. В советское время главной заслугой Цеткин считалось учреждение по ее предложению Международного женского дня.

Клара Цеткин, в девичестве Айснер, родилась в 1857 году в небольшом саксонском городке Видерау в семье сельского учителя. Уже в юном возрасте Клара выделялась среди сверстников любознательностью и цепкой памятью: в 9 лет девочка прочла всего Гете и Шиллера и с удовольствием декламировала их стихи, а в 12 - на память цитировала отрывки из "Истории французской революции" историка Томаса Карлейля.

Еще будучи студенткой Лейпцигской педагогической гимназии, престижного учебного заведения, она стала посещать тайные собрания социал-демократов. В это же время она познакомилась со своим будущим спутником жизни - русским революционером-эмигрантом Осипом Цеткиным, вместе с которым вскоре была вынуждена уехать в Цюрих, от усилившихся в Германии гонений на социалистов.

**Ислам** Габдрахманов,
6А класс

## Интересно знать!

♦ **8 Марта отметили** в России в первый раз в Петербурге в 1913 году.

♦ 1966 году **Международный женский день** стал официальным **праздником** .

♦В 1911 году международный женский день начал отмечаться в Германии, Австрии, Дании и Швейцарии.

♦ Этот праздник отмечали 19 марта до 1912 года. В 1912 году праздник был перенесён на 12 мая.

♦Умерла Клара Цеткин 20 июня 1933 года в подмосковном Архангельском в возрасте 76 лет.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Афганистан - наша память! | 2 |
| Ни өчен «Әлифба» музее Арчада ачылган ? | 2 |
| Наша гордость | 3 |
| Сынауларда сыналган туганлык. | 4 |
| Акчаны җилгә очыру кирәк? | 5 |
| Труженик тыла Танзиля Сагитова | 6 |

# Афганистан - наша память!

**Багаутдинов Сергей закончил Новокинерскую школу в 1979 году, занимался борьбой. Неоднократный призер и чемпион Республики по вольной и классической борьбе.**

В 1979 году поступал в Рязанское высшее воздушно-десантное командное училище но не поступил по конкурсу. В этом же году осенью был призван в ряды Советской Армии. Служил в ракетных войсках стратегического назначения. Во время службы выполнил 1 взрослый разряд по гиревому спорту.

После года службы написал рапорт для поступления в Рязанское высшее воздушно-десантное училище. В 1980 году успешно сдал экзамены и был зачислен курсантом на 1 курс.

В 1984 году закончил училище и был направлен в г. Псков в 76-ую гвардейскую воздушно-десантную дивизию. Служил в 6 парашютно-десантной роте, известную за бой на высоте 776 в 2000 году.

В 1987 году назначен на должность командира роты.

В 1988 году Сергей был направлен Афганистан на должность командира 2 роты 345-го отдельного парашютного десантного полка. За выполнение задач Родины, за мужество и героизм был награжден орденом «Красной звезды». В феврале 1989 года обеспечивал вывод Советских войск из Афганистана в составе своего полка. В 1989 году, вместе с полком, был переброшен в г. Кировабад. В составе полка выполнял задачи по разъединению враждующих сторон.

В 1992 году полк был переброшен в республику Абхазия для проведения миротворческой операции и урегулирования грузинско-абхазского конфликта. За выполнение задач Родины и правительства был награжден орденом «За военные заслуги», медалью «За отвагу».

В 1999 году уволен в запас по организационно-штатным мероприятиям.

В настоящее время Сергей Лемусович вносит свой вклад в военно-патриотическое воспитание подрастающего поколения.

«Афганистан - наша память и боль» - говорит Багаутдинов



С.Л. при встрече с учениками нашей школы.

Педагог—организатор
**Дина** Ибрагимова

# Ни өчен «Әлифба» музее Арчада ачылган?

**Арчаның икенче номерлы урта мәктәбенең 1«В» сыйныфы укучылары белән 2 нче март көнне Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенә экскурсиягә бардык.**

Безне «Әлифба» музееның житәкчесе Дамир Таҗиев каршы алды. Музей ишекләрен ачып кергәч тә, ул безне әлифба дөньясына алып кереп китте.

Музейда без татар телендә укырга, язарга өйрәтүче “Әлифба” дәреслегенең 200 еллык тарихы, аның авторлары, бөек татар галимнәре, педагогия училищесының татар теле һәм әдәбияты укытучылары Сәләй Вәгыйзев һәм анын тормыш иптәше Рәмзия Вәлитованың тормыш юлы, эшчәнлеге белән таныштык. Арчадагы «Әлифба»музее Европа, Азия, Африка, Америка илләренең әлифбаларын, азбукаларын, букварьларын узенә жыйган бердәнбер урын икәнен белдек. Үзебезне XIX-XX гасыр атмосферасында тойдык . Балалар башка илләрнең әлифбалары белән кызыксындылар. Биредә 57 телдә өч йөзләп әлифба бар икән. Музейда революциягә хәтле мәдрәсәдә ничек укыганнарын белдек. Дамир Таҗиев безне латин алфавиты белән дә таныштырып китте, укучылар үзләре дә сүзләр укып карадылар.

Музейның бер почмагында “Әлифба”дәреслегенең авторлары Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитоваларның эш урыннары да ачык чагылдырылган.

Балалар соңыннан бик рәхәтләнеп, Дамир абыйлары тәкъдим иткән квестлар,уеннарда катнаштылар.Татар теленә кызыксыну уята торган уеннарны үзләре дә өйрәнделәр.

Укучылар “Ни өчен Элифба музее Арчада ачылган?” дигән сорауга җавап таптылар. Рәхмәт, Арча педагогия коллективына, музей хезмәткәрләренә.

Без барлык укучылар да “Әлифба” музеенда булырга тиеш дигән фикер белән килдек

1«В» сыйныфының
укытучылары:
**Эльвира** Шарипова,
**Раушания** Бакиева.



# Наша гордость

***Наконец, прошли все республиканские этапы олимпиад. И каждая из них помогла выявить лучших учеников в определенных предметах. Лучшими среди лучших стали... МОЛОДЦЫ!!!***

| | |
|---|---|
| Литература | Шарипов Рузаль |
| Татарский язык | Аглиева Адиля |
| | Никитина Эльзана |
| | Шарипов Рузаль |
| Английский язык | Газизов Данил |
| МХК | Газизов Данил |

## Фоторепортаж с мероприятий текущего месяца











# Сынауларда сыналган туганлык.



**Станция зиратында әфган сугышында һәлак булган якташыбыз Марат Лотфуллин җәсәде җирләнгән.**

**...**Очрашу вакыты сәгать унга дип билгеләнгән иде. Иртәдән яңгыр коя, якшәмбә көн дә бит әле, күңелдә "Килерләрме икән?" дигән шик тә туып алды. Әмма сүз әфганчылар турында бара, яңгырда гына түгел, дошман пулясы астында йөргән кешеләр бит алар. Билгеләнгән вакытка бар да җыелып бетте. "Яңгыр сәгать унга туктый ул", - дип шаярышып та алдык. Шулай булып чыкты да.

Җыелышып беткәнче шәһәрнең көньяк мәчете имам – хайтыбы Хәлим хәзрәт белән сөйләшеп тордым. "Бу кешеләрнең бердәмлегенә сокланырлык", - диде ул, - Кайберәүләр килә дә: " Әти – әниенең кабере кайсысы икән?" – дип сорый.Таба алмасалар безне сүгеп тә китәләр әле. Ә болар андый түгел".

Марат Лотфуллин Арчаның 2нче урта мәктәбен тәмамлап Казандагы төзүчеләр институтына укырга кергән булган. Әмма аңа калалар төзү насыйп булмый, әфган сугышы башлана. Танкист егетнең гомере шунда өзелә.

Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел, диләр. Хәлим хәзрәт үзенең вагазендә "Хаҗга барган кешеләрнең ни кичергәнен хаҗда булган кеше генә белә, диләр. Әфган сугышында булган кешеләрнең ниләр кичергәнен анда булганнар гына аңлый", - диде. Менә шуңа күрә дә хәрби хезмәт ветераннарын берләштергән җәмәгать оешмасы "Сугышчан туганлык"дип атала. Аларның туганлыгы "кайнар нокталарда" сыналган, какшамас, мәңгелек. Әлеге оешма җитәкчесе Сергей Баһаветдинов, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Арча һәм Әтнә районнары буенча җитәкчесе Алмаз Борһанов менә шушы туганлыкның ничек барлыкка килгәнлеге, ир – егетләрнең Ватан алдындагы изге бурычлары, Маратның батырлыгы турында сөйләделәр. Сыйныф җитәкчесе, Татьяна Егорованың үзенең укучысы турында хатирәләрен уртаклашканда күзләре яшьле иде. Маратның әнисе Илсөя апа хастаханәдә авырып ята. Баласын югалткан ана гомере буе яралы кош кебек, берәүнең дә йөрәге тимер түгел...

-Без әфган җирендә башларын салган өч якташыбызның чардуганнарын, ташларын яңартып чыгабыз, - ди Сергей Баһаветдинов. – Марат Лотфуллин каберендәгесен яңарттык. 9 майга кадәр калганнарын да эшләп куячакбыз.

Марат Лотфуллин истәлегенә үткәрелгән чарага директор Гөлназ Гыйниятуллина җитәкчелегндә 2нче урта мәктәп укытучылары, укучылары да килгән иде. Мәктәптә батыр якташыбыз истәлеген кадерләп саклыйлар, аның белән горурланалар.

**Ильяс** Сәхәпов,
"Арча хәбәрләре" 14 сентябрь, 2016 ел

# Кем ул Марат Лотфуллин?



"Бердәм Россия" сәяси партиясенең җирле бүлекчәсе "Геройлар урманнары" проектны нигезендә игелекле эш башкара. Проектның максаты – геройларны искә алу, алар белән халыкны таныштыру, ватанпәрвәрлек рухында яшьләрне тәрбияләү. Арча станциясендәге яңа 9нчы балалар бакчасында ("Шатлык") эти-әниләр, балалар белән үткәрелгән истәлекле урам бәйрәме шуның ачык мисалы.

Марат турында күбрәк беләсе килә. Бергә уйнап үскән малайлар, сыйныфташлар, сыйныф җитәкчесе – кемнәр алар?

Сыйныф җитәкчесе – абруйлы математика укытучысы Татьяна Александровна Егорова. Яңа гына Сочидан кайтып төшкән иде.

Арча станциясендә мәчеттән өстәрәк Марат Лотфуллин урамы бар. Кем ул Марат Лотфуллин? Ни өчен урамны аның исеме белән атаганнар? Белгәннәр, Әфганстан сугышында һәлак булган егет, диләр. Очрашуга әнисе Илсөя апа да килгән иде. Аз сүзле ана улы турында әллә ни сөйли алмады.

-Бик сагынам, - диде, - Үзем генә яшим. Кызым үз гаиләсе белән көн итә. Улым башкалардан аерылып торган бала булмады, тыйнак, гади иде. Укытучысы аның турында:

-Маратны ничек хәтерләмим инде, билгеле, хәтерлим, - дип сөйләде. – "4"кә, "5"кә генә укыды. Тыйнак, тырыш, сүз тыңлаучан бала иде. 1985 елда мәктәпне тәмамлады. Үз тырышлыгы белән Казан төзүчеләр институтына укырга керде. Быел менә мәктәпне тәмамлауларына 30 ел була. Юбилей елы. Сыйныфташы Рамил Гыйниятов белән кара-каршы гына яшәделәр, дус булдылар. Фото, видеоларга төшерүче Ринат Минһаҗев та аның сыйнфташы. "Арча нефть продуктлары" җәмгыяте ашханәсендә эшләүче Розалия, "Казан аптекасы"нда хезмәт итүче Сәрия газчы Эдуард Газизов – алар бар да бергә укыды.

Ринат Минһаҗевны да эзләп таптык.

-Марат Тукай урамында яшәде, мин - Азин урамында, дип сөйләде җирле бүлекчәсе башкарма комитеты җитәкчесе Тәлгать Җәләлетдинов Илсөя апаның иңнәренә ак шәл салды. Бакча мөдире Надия Мифтахетдинова анага чәчәкләр бүләк итте. Педагог Гөлнара Гәрәева "Су буеннан әнкәй кайтып килә..." җырын бик матур итеп башкарды. "Бердем Россия" партиясе җирле бүлекчәсе башкарма комитеты җитәкчәсе урынбасары Валентина Гаранина, Арча станциясендәге мәдәни-спорт үзәгенең сәнгать җитәкчесе Илмира Фазылҗанова герой турында сөйләде, китапханәче Любовь Капралова балаларны уйнатып та алды. Соңыннан бергәләп фотога төштеләр. Надия Равилевна кунакларны балалар бакчасы белән таныштарды, чәй өстәле янында сөйләшеп утырдылар. Бик кызганыч, исән булса, бу бакчага Маратның оныклары йөргән булыр иде.

**Румия** Надршина,
"Арча хәбәрләре"
24 июль, 2015 ел

# Акчаны җилгә очыру кирәк?

***Онытылмаслык хисләр ташкыны өчен аны олылар да, кечеләр дә бик ярата, ул куплэрне башта куркыта, әмма бик тиз соклану хисе тудыра башлый. Бу очракта хәтта акчаны җилгә очыру да бары тик уңай тәэсирләр генә бүләк итә! Әле һаман аңламадыгызмы? Сүзем кешене дә күкләргә күтәрә алырлык көчле аэроторба турында!***

Элек астронавт һәм очучыларга гына билгеле булган җайланмада бүген теләгән һәркем үзенең очу сәләтен сынап карый ала. Алай гына да түгел, барлыкка килгән һава агымы үзеңне парашютист урынында хис итәргә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә парашют белән сикерергә курыкканнар өчен аэроторба «канат кагар» өчен менә дигән мөмкинлек.

Биредә һаваның тизлеге кешенең үзен тотуына карап көйләнә. Бу адым уңышлы үтәлгәч, очучы төрле хәрәкәтләргә дә керешә ала: “лотос” позасында, басып, ятып, баш белән аска дисеңме... монда барысы да синең тәҗрибәңнән һәм физик халәтеңнән тора.

Ә очыш сыйфаты исә инструктажны ни дәрәҗәдә игътибар белән тыңлауга бәйле. Әйтик, хатын-кызлар аэроторбада күпкә яхшырак оча, бу аларның артык борчылудан инструктор тәкъдимнәрен яхшылап тыңлауларына бәйле, ә ир-егетләр авыр очракларда үзләренә таянырга өйрәнгән була, шуңа күрә бу эштә дә ярдәм итүне кәтми.

Аэроторбада 4 яшьлек балалар да очарга өйрәнә ала. Шунысы кызык, олыларга караганда алар бу эшне күпкә яхшырак та башкара әле, чөнки бу яшьтә балаларда җир рефлекслары гадәттә югары күтәрелеш алмаган була.

Әлеге шөгыльнең популярлыгы да көннән-көн арта бара, шуңа күрә аэроторбада «дебютчылар» белән беррәттән профессиональ спортчылар да шөгыльләнә ала. Бүген инде анысы да аерым спорт төре буларак формалаша башлады.

Әле күптән түгел генә Испаниядә мондый җайланма эчләрендә «WindGames» дип аталган бию бәйгеләре дә үткәрелә башлаган икән. 2016 елда Россия спортчысы Леонид Волков та әлеге уен буенча Дөнья чемпионы исеменә лаек булган.

«Берничә ел элек бары тик экстрим алыр өчен генә парашют белән сикерергә, акваланг белән су астына төшәргә булдым. Ләкин һавада очу күбрәк ошаганга, парашютлар белән кызыксынуым мавыгуыма әверелде, – дип уртаклаша «Вертолёт» аэроторбасы инструкторы Илнар Монасыпов. – Ул вакыйгалардан бер ел да үтмәгәндер, бу юнәлешне профессиональ рәвештә үзләштерә башладым. Бүген инде парашют белән якынча 200 тапкыр сикергәнем бар. Аларның һәркайсы күңелгә үзенчә якын, чөнки сикерү һәрвакыт яңа тәэсирләр бүләк итә! Аэроторбада очканда да шундыйрак хисләр барлыкка килә».

Беренче очыш синдә дә бары уңай хисләр генә калдырсын өчен тәҗрибәле тренер Илнар Монасыповтан сиңа берничә лайфхак.

### ЛАЙФХАК №1

Әлеге төр күңел ачуны иптәшләрсез күз алдына китерү мөмкин түгел диярлек. Биредә алар сиңа көч бирә, үзеңә ышанычны арттыра. Дусларың беренче тапкыр җирдән аерылуыңны фото-видеога төшереп, матур истәлек итеп сакларга да ярдәм итәр.

### ЛАЙФХАК №2

Спортчылар аэроторбада үзләрен шактый иркен тота. Әле алай гына да түгел, аэроторба үзе дә спорт белән шөгыльләнергә мөмкинлек тудыра, чөнки очканда барлык мускуллар да эшли башлый. Шуңа күрә биредә шөгыльләнү спортзалда ясала торган күнегүләрне дә алыштыра ала. Беренче очышта югары нәтиҗәгә ирешү кыен булыр, тик алга таба аның вакытын озайтып, үзеңнең очу осталыгыңны яхшыртырга мөмкин.

### ЛАЙФХАК №3

Беренче тапкырга очуны 4-10 минуттан да арттырырга киңәш ителми. Ә аэроторбада гомумән алганда 30 минуттан артык шөгыльләнгәнең булса, синең җайланмада инструкторсыз да очу мөмкинлегең барлыкка килә.

### ЛАЙФХАК №4

Аэроторбада парашют спортын профессиональ рәвештә үзләштерү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган, шуңа күрә биредә бер дә курыкмыйча төрле хәрәкәтләр ясарга өйрәнеп була. Тик беренче тапкыр парашют белән сикерү өчен аэроторбада очу мәҗбүри түгел, чөнки аэродромда барыбер тиешле әзерлек үтү мөмкинлеге булачак.

Һәм... хыялыңны чынга ашырырга курыкма! Яхшы кәеф, уңайлы кием турында да онытма!

**P.S.** Уйладым да, парашют белән сикерергә булдым әле. Әни бик озак мине күндерергә тырышты, эти исә: «Бу һәркем өчен бик кыю адым. Баскычтан төшкәндә аягын сындырган кешегә аеруча!» диде. Шуңа күрә аэроторбада гына очып торырмын ахрысы…

**Рүзәл** Шәрипов, 10 сыйныф



# Труженик тыла
# Танзиля Сагитова



Танзиля Исламовна родилась 26 октября 1926 года в деревне Айван Арского района.

К сожалению, своего отца она не помнит, он умер, когда ей было всего шестой год жизни. Мама всю жизнь проработала в колхозе.

Своё детство Танзиля провела в деревни Айвань. В их семье было 8 детей: 7 девочек и 1 мальчик. Она была вторым ребёнком, помогала маме по хозяйству. 1933 году пошла в первый класс в среднюю школу, которая находилась в деревне Качелино. В 1940 году окончила семь классов в этой же школе и поступила в педагогическое училище в деревне Лесхоз в факультет учителей начальных классов. Вспоминая свои студенческие годы, рассказывает такую ситуацию: если студент получит «2» за четверть, то его исключали. Перед экзаменами их осталось двое учеников. Один студент получил «2» за четверть и его исключили. Поэтому Танзиля сдавала экзамены одна. Когда началась война, ей пришлось одновременно и учиться и работать в средней школе деревне Лесхоз. Танзиля окончила обучение в 1945 году.

У Танзили Исламовны 4 детей: 2 мальчика и 2 девочки. Их зовут Рашид, Марат, Ляйсан, Нурия.

В этом году Танзиле Исламовне исполнится 94 года. Мы ей долгих лет, тепла желаем!

**Камиль** Гарифуллин, 6 А класс



2 марта ученики 1 "В"класса вместе с кл. руководителем Э.Р. Шариповой и воспитателем продленного дня Р.К. Бакиевой посетили уникальный в мире музей, посвященный татарскому букварю "Әлифба", который располагается в Арском педогогическом колледже им. Г.Тукая.

Здесь ученики узнали про возникновение и развитие письменности народов мира с древнейших времён до наших дней, о различных системах, графики и алфавита.

Участие отряда "Волонтеры Победы



МБОУ АСОШ №2" в районном добровольческом форуме "Волонтеры Победы" Арского муниципального района РТ, посвещенного 75 - летию Победы в Великой Отечественной войне 1941 — 1945 гг. И 100—летию образования ТАССР.


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов

***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов

***Корректор*** Ислам Габдрахманов

***Редколлегия*** Раниль Заляев
Камиль Гарифуллин